**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 308

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «_29_» _апрелендәге_
_308_ номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге (алга таба шулай ук – Бүлек) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Бүлек Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

4. Бүлек турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

II. Бүлекнең төп бурычлары

5. Бүлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенең иҗтимагый әһәмияткә ия чараларда, очрашуларда, эш сәфәрләрендә чыгышлары текстлары һәм тезислары проектларын әзерләү өлешендә Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе кул куя торган котлау документлары проектларын, шулай ук кайгы уртаклашу белдерелгән хатлар һәм телеграммалар проектларын әзерләү.

## III. Бүлекнең төп функцияләре

6. Бүлекнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенең иҗтимагый әһәмияткә ия чараларда, очрашуларда, эш сәфәрләрендә чыгышлары текстлары һәм тезислары проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенең халык алдында чыгышлары текстлары проектларын эчтәлек һәм стилистикага кагылышлы өлештә редакцияләү;

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенең төрле тематик юнәлештәге проектлары текстларын системага салу, әлеге проектлар базаларын булдыру һәм алып бару;

ай саен Татарстан Республикасы белән багланышта торган чит ил дәүләтләрендәге һәм Россия Федерациясе субъектларындагы күренекле даталар һәм вакыйгаларның дипломатик календарьларын төзү;

Татарстан Республикасы Рәисе исеменнән чит ил дәүләтләрендәге, Россия Федерациясендәге дәүләт бәйрәмнәре, күренекле вакыйгалар, оешмаларның һәм күренекле шәхесләрнең юбилей даталары белән котлау документлары проектларын әзерләү;

чит илләрдә һәм Россия Федерациясендә фаҗигале вакыйгалар, шулай ук чит илләрнең күренекле дәүләт эшлеклеләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, фән, мәгариф, мәдәният, спорт әһелләре вафат булу сәбәпле Татарстан Республикасы Рәисе исеменнән кайгы уртаклашу хатлары һәм телеграммалары проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасының еллык даталар һәм вакыйгалар календарен әзерләүдә катнашу.

Бүлек Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча башка функцияләрне башкара.

## IV. Бүлекнең хокуклары

7. Үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен Бүлек түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фәнни һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## V. Бүлекнең хезмәттәшлек итү даирәсе

8. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Бүлек Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

9. Бүлек хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

## VII. Бүлек эшчәнлеген оештыру

10. Бүлекнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

11. Бүлек эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге мөдире (алга таба – Бүлек мөдире) җитәкчелек итә, ул Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы белән вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

12. Бүлек мөдире:

Бүлек эшен оештыра; Бүлеккә йөкләнгән бурычларның үтәлүенә җаваплы була;

Бүлекнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Бүлек хезмәткәрләре арасында вазыйфаи йөкләмәләрне бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Бүлекнең структурасы, штат саны, хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую, вазыйфадан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Бүлек хезмәткәрләрен бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылыкка тарту турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе уздырган утырышларда Бүлек компетенциясенә кагылышлы сораулар буенча фикер алышуларда катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Бүлек вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

13. Бүлек мөдире вакытлыча эш урынында булмаган вакытта, аның вазыйфаларын Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

14. Бүлек хезмәткәрләре Бүлек мөдире тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

___________